КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 май г.Казань № 676

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче, 2021 ел, 1 сентябрь, 801 нче, 2022 ел, 5 май, 417 нче, 2022 ел, 16 май, 446 нчы, 2022 ел, 7 июль, 651 нче, 2023 ел, 19 май, 609 нчы, 2023 ел, 6 октябрь, 1254 нче, 2024 ел, 15 март, 148 нче, 2024 ел, 4 сентябрь, 727 нче, 2025 ел, 10 март, 142 нче, 2025 ел, 3 июнь, 399 нчы, 2025 ел, 23 июль, 543 нче, 2025 ел, 30 декабрь, 1226 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарына һәм шәһәр округларына балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча хезмәт күрсәтүләр күләмнәре нормативларын ел саен җиткерү һәм балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыруга Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү турында килешүләр төзү эшләре;»;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктта «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 пунктта:

алтынчы абзацта «30» саннарын «35» саннарына алмаштырырга;

уналтынчы абзацта «30» саннарын «35» саннарына алмаштырырга;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланган түбәндәге чараларны оештыручы булып тора:

югары белем бирү мәгариф оешмаларының 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге (35 яшьне кертеп) студентлары өчен физкультура-массакүләм чаралар;

Өстәмә гомуми белем бирү, гоумуми үстерү һәм һөнәр алды программалары буенча укучы, үзләштерүче иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар, спорт әзерлеге узучы балалар, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара һәм төбәкара килешүләрен гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе субъектларыннан һәм якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелгән 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге (35 яшьне кертеп) балалар һәм яшьләр өчен шәһәр яны ял лагерьларында, шул исәптән Российя Федерациясендә диңгез яр буйларында, профильле сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге сменалар үткәрелде;

өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче, укучы иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар өчен палатка тибындагы лагерьларда, хәрби-патриотик тәрбиягә юнәлтелгән сменаларда 7 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге катнашучылар өчен;

авыр тормыш хәлендә калган 7 яшьтән 15 яшькә (15 яшьне кертеп) кадәрге балалар өчен шәһәр яны ял һәм сәламәтләндерү лагеренда, шул исәптән Россия Федерациясенең диңгез яр буенда смена;

7 дән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең балалары өчен шәһәр яны ял итү һәм сәламәтләндерү лагеренда (дәүләт һәм муниципаль оешмалардан тыш) смена.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Җәй» балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне, ял иттерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе законнар белән билгеләнә торган тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә урнашкан ял оешмасында балалар һәм яшьләр өчен юлламалар сатып алуга контрактлар (килешүләр) төзи, шул исәптән балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Черноморец» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе законнар белән билгеләнә торган тәртиптә Россия Федерациясенең диңгез ярында урнашкан ял оешмасында балалар һәм яшьләр өчен юлламалар сатып алуга контрактлар (килешүләр) төзи, шул исәптән балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы квартал саен тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре чикләрендә финанслауның иң чик күләмнәрен, бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләменнән квартал саен түбәндәгечә бүлеп бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларын Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына җиткерә:

I квартал (5 февральгә кадәр) – 20 процент;

II квартал (5 апрельгә кадәр) – 50 процент;

III квартал (5 июльгә кадәр) – 20 процент;

IV квартал (5 ноябрьгә кадәр) – 10 процент.»;

3.4 пунктның җиденче абзацында «30» саннарын «35» саннарына алмаштырырга;

3.6 пунктның дүртенче абзацында «30» саннарын «35» саннарына алмаштырырга;

3.7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктның икенче абзацына «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендәге махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләреннән балаларның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак булган (үлгән) югары категорияләрдәге гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) ялын һәм аларны савыктыруны оештыру» сүзләрен өстәргә;

4.5 пунктның икенче абзацына «; югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары өчен физкультура-савыктыру чараларында» сүзләрн өстәргә;

13.4 пунктта «ял оешмасы» сүзләрен «балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыру сменаларын оештыручы» сүзләренә алмаштырырга;

14.2 пунктта «30» саннарын «35» саннарына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының каникул вакытында балалар ялын оештыру буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 23 гыйнвар, 25 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының каникул вакытында балалар ялын оештыру буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«каникуллар вакытында балаларның ялын оештыру буенча чаралар исемлеген үз эченә алган каникуллар вакытында балаларның ялын оештыру буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр бирү турында килешү белән билгеләнә торган субсидияләрдән файдалануның максатчан күрсәткечләре (нәтиҗәләре) булган муниципаль программа булу (алга таба - килешү);»;

12 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$N_{ij}$ – балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәтләр күләме;»;

бишенче абзацта «төбәк проекты белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацта «, төбәк проектына туры китереп» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Бу карарның 1 пунктындагы икенче һәм өченче абзацлары гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин